Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

Аграмак авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 1 09.01.2017 ел.

**“Аграмак авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм башкару турында” нигезләмәне раслау турында.**

Россия Федерациясе Конституциясе, "Оборона турында « 1996 елның 61-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында» 1997 елның 31-ФЗ номерлы федераль закон, 1998 елның 53-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»,2003 елгы 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” федераль законнары, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы « хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып:

1.“Аграмак авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм башкару турында” нигезләмәне расларга.
2. Хәрби исәп буенча хезмәткәрнең вазифаи бурычларын расларга.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Спас муниципаль районы Аграмак авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: Р.Т.Галәветдинова

# “Аграмак авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм башкару турында” нигезләмә.

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Аграмак авыл җирлегенең Хәрби исәп буенча хезмәткәре җирлек территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыра.
1.2. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, "Оборона турында « 1996 елның 61-ФЗ номерлы федераль законы, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында» 1997 елның 31-ФЗ номерлы федераль закон, 1998 елның 53-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында»,2003 елгы 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” федераль законнары, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы « хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары, "Вәкаләтләрне чикләүне камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2005 елның 31 декабрендәге 199-ФЗ номерлы Федераль законы, “Мобилизацияләү чорында һәм хәрби вакытта Россия Федерациясе Кораллы Көчләрен, федераль башкарма хакимият органнары запасын тәшкил итүче Россия Федерациясе гражданнарын, һәм дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда эшләүчеләрне броньлау буенча инструкция”гә, Татарстан Республикасы законнарына, җирле үзидарә органы Уставына, һәм башка норматив хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.
1.3. Нигезләмә Җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан раслана.

## II. Төп бурычлары

2.1. Хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәрнең төп бурычлары:
Гражданнар тарафыннан, "Оборона турында", "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында", "Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында" федераль законнар белән билгеләнгән хәрби бурычның үтәлешен тәэмин итү;
Хәрби исәптә торучы гражданнар турында хәрби исәпкә алу мәгълүматларын документаль рәсмиләштерү;
ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле файдалану өчен хәрби хезмәткә чакырылучы кеше ресурсларының санлы составын һәм сыйфатлы торышын анализлау;

Россия Федерациясе Кораллы көчләрен, башка гаскәрләрне, хәрби формированиеләрне һәм органнарны хәрби вакытка күчерүне оештыру өчен запастагы хәрби исәпкә алынган гражданнарны әзерләү, мобилизацияләү буенча, һәм аларны хәрби вакытта таләп ителә торган дәрәҗәдә тәэмин итү чараларын тәэмин итү өчен планлы эш алып бару.

**III. Функцияләре**

3.1. Җирле үзидарә органы администрациясендә эшләүче гражданнар арасыннан беренчел хәрби исәпкә алу, хәрби исәпкә алу һәм броньлау буенча көндәлек эшчәнлектә хакимияткә йөкләнгән функцияләрне үтәүне тәэмин итү;

3.2. Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядә яшәүче яки вакытлыча (3 айдан артык вакытка) яшәүче, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар һәм запастагы гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга;

3.3. Эчке эшләр органнары белән берлектә Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядә даими яки вакытлыча яшәүче хәрби исәптә торырга тиешле гражданнарны ачыкларга;

3.4. Җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориядәге оешмаларда хәрби исәпкә алуның алып барылышын контрольдә тотарга;

3.5. Елга бер тапкырдан да ким булмаган арада беренчел хәрби исәпкә алу документларын муниципаль берәмлек хәрби комиссариатының, оешмаларның хәрби исәп документлары, шулай ук теркәү карточкалары яки йорт кенәгәләре белән чагыштыру;

3.6. Муниципаль берәмлек хәрби комиссариаты кушуы буенча гражданнарга хәрби комиссариатка чакыру турында хәбәр итәргә;

3.7. Беренчел хәрби исәпкә алу документларында булган мәгълүматларга үз вакытында үзгәрешләр кертергә һәм хәрби комиссариатка кертелгән үзгәрешләр турында ике атна эчендә хәбәр итәргә;

3.8. Ел саен хәрби комиссариатка 1 ноябрьгә кадәр 15 һәм 16 яшьлек егетләр исемлеген, ә 1 октябрьгә кадәр-киләсе елда хәрби исәпкә куелырга тиешле егетләр исемлеген тәкъдим итәргә;

3.9. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга аларның хәрби исәпкә алу, мобилизация әзерләү һәм мобилизацияләү буенча Россия Федерациясе законнары һәм хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән бурычларын аңлатырга һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга.

**IV. Хокуклары**

4.1. Хәрби исәпкә алу хезмәткәре планлы һәм максатчан эш алып бару өчен: билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимиятенең федераль органнарыннан, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарыннан,

җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә учреждениеләр һәм оешмалардан кирәкле материалларны һәм мәгълүматны соратып алу буенча тәкъдимнәр кертергә;
җирле үзидарә органы администрациясенең структур бүлекчәләреннән аналитик материаллар, чараларның җыелма планнары буенча тәкъдимнәр һәм аларның үтәлеше турында мәгълүмат, шулай ук хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәргә йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле башка материалларны соратып алырга;
хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәр компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмат базасын булдыру;
килешү нигезендә аерым эшләрне башкару өчен белгечләрне җәлеп итү турындагы мәсьәләләрне җирле үзидарә органы җитәкчесенә җиткерергә;
хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәр компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча башкарма хакимиятнең федераль органнары, Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук оешмалар белән билгеләнгән тәртиптә үзара хезмәттәшлекне оештыру һәм эш буенча язышуын тәэмин итү;
хәрби хисап буенча хезмәткәр компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Эчке киңәшмәләр үткәрүгә хокуклы.

## V. Җитәкчелек

5.1. Хәрби исәпкә алу өчен җаваплы- Аграмак авыл җирлегенең хәрби исәпкә алу буенча белгече Барышева Наталья Вячеславовна.
5.2. Хәрби исәпкә алу буенча белгеч Аграмак авыл җирлегенең турыдан-туры буйсынуында тора;
5.3. Хәрби исәпкә алу буенча хезмәткәр җитди сәбәпләр аркасында эш урынында булмаган очракта (отпускка, вакытлыча эшкә сәләтсезлек, командировка) аны секретарь Семенова Ирина Владимировна алыштыра.

Аграмак авыл җирлегендә
хәрби исәпкә алу өчен җаваплы ________ Н. В. Барышева